СОВЕТ КАТМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Киров урамы, 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы, 422177

тел.(факс): (85563) 2-72-03; e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

« 15 » мая 2017 года — № 1-22

# Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең 2016 елның 3 мартындагы 1-7 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, 2016 елның 29 сентябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 һәм 42 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 22 февралендәге 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Катмыш авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең 2016 елның 3 мартындагы 1-7 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3.6 статьяга түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

2018 елның 1 гыйнварына кадәр авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә һәм стажына түбәндәге квалификация таләпләре билгеләнә: урта һөнәри белем һәм муниципаль хезмәт стажы булу яки белгечлек буенча эш стажы ике елдан да ким түгел яки өч елдан да ким түгел.

Белгеч яки магистр дипломы булган затлар өчен диплом бирелгән көннән алып өч ел дәвамында муниципаль хезмәт стажына яки муниципаль

хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфаларын биләү өчен белгечлек буенча эш стажына квалификация таләпләре билгеләнә - муниципаль хезмәт стажының ярты елыннан да ким булмаган яки белгечлек буенча бер ел эш стажы.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында mamadysh.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башлыгы И.Г.Габидуллинга йөкләргә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге Советы рәисе / И.Г.Габидуллин/